**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422610 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПӘРӘҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422610 Пәрәү,
Совет урамы, 9 нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**№8** **2019 елның 15 апреленнән**

# КАРАР

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Пәрәү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә
тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварыннан №8-ФЗ “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварыннан №32 “2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында”гы карарына, 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы ТР Законына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2007 елның 18 маеннан №196 “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында”гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында”гы карарына, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы төстә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен 1нче һәм 2нче кушымталарга ярашлы төстә 2019 елның 1 февраленнән 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Пәрәү авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе**

**вазифаларын башкаручы** **Р.Г.Евдокимова**